**3- вариант**

**II бүлек**

**Ак песи**

1) Идел-елга буенда зәңгәр тәрәзәле, зәңгәр капкалы бик матур бер йорт булган. 2) Шушы йортта бик тә матур, кеп-кечкенә ике песи баласы торган. 3) Аларның берсе ап-ак мамыктай күперенке тунлы, үзе күк күзле, үзе бик үзсүзле булган. 4) Икенчесе аклы-сорылы, күзе дә соры, әмма үзе бик акыллы, тыйнак һәм сүз тыңлаучан икән.

5) Шушы ике песи баласыннан башка бу матур йортта ап-ак чәчле, йомшак сүзле, ягымлы йөзле бер әби дә яшәгән. 6) Янында бик җитез һәм бик шаян бер оныгы да бар икән.

7) Бу кызчык тузгып торган сап-сары чәченә күбәләк кебек зәңгәр тасма тагып йөри. 8) Ак песинең муенына да зәңгәр тасма бәйләп куя икән. 9) Кызчык Ак песине ярата, аны кочаклап йоклата, үзе ашаганны гына ашата, кәгазь күбәләкләр ясап уйната икән. 10) Әби Соры песи баласын артыграк яраткан, «Акыллым», - дип кенә йөрткән.

11)Бервакыт бу песиләр, икесе бергә зәңгәр чынаяктан сөт эчеп торганда, баскыч төбендә кечкенә генә кап-кара бер көчекне күреп алганнар.

12)Ак песи, көчекне күрүгә, ап-ак сыртын кабартып, күк күзләрендә зәңгәр очкыннар уйнаткан: «Кит моннан!» - дип ысылдаган.

*13)Соры песи туганының бу сүзләре өчен оялган һәм зәңгәр баскычтан сикереп төшкән дә:*

*14)- Курыкма син аннан, эч сөтне, эч! 15) Үсмәгән әле ул, дуслыкның да, ачлыкның да нәрсә икәнен белми, - дигән*. 16) Шуннан Кара көчек, курка-курка, сөтне эчә башлаган.

*(Резеда Вәдиевадан)*

**2 - 1 0 нчы биремнәрнең җавабын сүз (сүзтезмә) яки цифр белән күрсәтегез.**

**2**. Сингармонизм законынының **рәт гармониясенә буйсынмаган** сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез.

1)Ак песинең муенына да зәңгәр тасма бәйләп куя икән.

2) Кызчык Ак песине ярата, аны кочаклап йоклата, үзе ашаганны гына ашата, кәгазь күбәләкләр ясап уйната икән.

3)Бервакыт бу песиләр, икесе бергә зәңгәр чынаяктан сөт эчеп торганда, баскыч төбендә кечкенә генә кап-кара бер көчекне күреп алганнар.

4)Шуннан Кара көчек, курка-курка, сөтне эчә башлаган.

**3.Күчерелмә мәгънәле** сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез.

1) Идел-елга буенда зәңгәр тәрәзәле, зәңгәр капкалы бик матур бер йорт булган.
2) Шушы йортта бик тә матур, кеп-кечкенә ике песи баласы торган.
3) Шушы ике песи баласыннан башка бу матур йортта ап-ак чәчле, йомшак сүзле, ягымлы йөзле бер әби дә яшәгән.
4) Янында бик җитез һәм бик шаян бер оныгы да бар икән.

**4.** 5 **-** 11 нче җөмләләрдән **ясалма исемне** табып языгыз.

**5.** 5 - 10 нчы җөмләләрдән **чагыштыру дәрәҗәсендәге рәвешне** табып языгыз.

**6.** **1**5 нче җөмләдән *кечкенә* сүзенең **синонимын** табып языгыз.

**7.** 16 нчы җөмләдән **тәмамлыкны** күчереп языгыз.

**8.** **1** - 9 нчы җөмләләрдән **иярченле кушма җөмләнең** номерын языгыз.

**9.** Түбәндәге җөмләдә барлык тыныш билгеләре номерланган. **Тиңдәш кисәкләр арасына** куелган тыныш билгесенең номерын языгыз.Икенчесе аклы-сорылы,[1] күзе дә соры,[2] әмма үзе бик акыллы,[3] тыйнак һәм сүз тыңлаучан икән.[4]

**10.** 12-14 нче җөмләләрдән **кире сүз тәртибе** кулланылган җөмләнең номерын языгыз.

III бүлек

2 нче бүлектә укылган тексттан файдаланып, 11.1 һәм 11.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.

11.1 “*Соры песи туганының бу сүзләре өчен оялган һәм зәңгәр баскычтан сикереп төшкән дә:*
*- Курыкма син аннан, эч сөтне, эч! Үсмәгән әле ул, дуслыкның да, ачлыкның да нәрсә икәнен белми, - дигән* ” юлларында әйтелгән фикерне сез ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан 2 мисал китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез. Сочинениенең күләме 50 сүздән дә ким булмаска тиеш. Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз